КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 апрель г.Казань № 208

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә тармак инфраструктурасын оптимальләштерү турында

Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү өлкәсендәге тармак инфраструктурасын Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары эшчәнлеген оештыру стандартын раслау турында» 2023 елның 16 мартындагы 156 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары эшчәнлеген оештыру стандарты белән туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләрен аларны кушу һәм алар базасында «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен (алга таба - Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) төзү рәвешендә үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге эшчәнлегенең төп максаты Татарстан Республикасы территориясендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның һәм эш бирүчеләрнең хокукларын һәм гарантияләрен тәэмин итү, шул исәптән гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, аларның һөнәри күнекмәләрен һәм компетенцияләрен үстерүдә, эшкуарлык инициативасын үстерүдә, эшсез гражданнарны социаль яклауда, эш бирүчеләргә хезмәткәрләрне сайлап алуда, гражданнарга һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирүдә һәм консультацияләүдә, гамәлдәге һәм яңа эш урыннары булдыручы эш бирүчеләргә ярдәм күрсәтү юлы белән;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге хезмәтенең 1 нче кушымтада күрсәтелгән дәүләт учреждениеләре хокуклары һәм бурычлары күчә;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге хезмәткәрләренең иң чик штат саны 760 берәмлек тәшкил итә;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге функциясен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләрен үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар уздыруны, шул исәптән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге уставын расларга;

эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге структурасын расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә эшчәнлек алып баручы халыкны эш белән тәэмин итүнең территориаль үзәкләре, хезмәткә сәләтле яшьтәге халык санына карап (алга таба - халыкны эш белән тәэмин итү территориаль үзәкләре);

халыкны эш белән тәэмин итү территориаль үзәкләре белән үзәкләштерелгән идарә итүне гамәлгә ашыручы бүлек;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләрен үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;consultantplus://offline/ref=D291F0DCE4D72F741618E84B3077CBFAB4E7635DD37182C87B963EEA59CBC8C6486DDBD4AF5C0E22BA759DF4EDH3sFH

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 09 август, 553 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруга «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган чаралар чикләрендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләрен үзгәртеп оештыру чараларын үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә Татарстан Республикасы күчемле дәүләт мөлкәтен беркетү турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук 2 нче кушымтада күрсәтелгән күчемсез милек объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына эш көннәрендә исәпләнгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәген законнарда билгеләнгән тәртиптә беркетү турында тәкъдимнәр биргән көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге структурасы һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге уставы расланганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр тапшырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшләүчеләрнең иң чик санын билгеләү турында» 2009 ел, 20 июль, 503 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшләүчеләрнең иң чик санын билгеләү турында» 2009 ел, 20 июль, 503 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2010 ел, 22 гыйнвар, 32 нче;

8. Бу карар 2024 елның 1 апреленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 апрель, 208 нче карарына 1 нче кушымта

Аларны кушу формасында үзгәртеп кору юлы белән «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе төзелә торган Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре исемлеге

423330, Азнакай шәһәре, Төзүчеләр урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан “Азнакай шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” дәүләт казна учреждениесе;

423060, Аксубай районы, Аксубай шәһәр тибындагы поселогы, Романов ур., 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Аксубай районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423740, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 61 нче йорт адресы буенча урнашкан “Актаныш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” дәүләт казна учреждениесе;

422900, Алексеевск районы, Алексеевск штп., Ленин ур., 87 нче йорт адресы буенча урнашкан «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422870, Әлки районы, Базарлы Матак авылы, Совет ур., 8 нче йорт адресы буенча урнашкан «Әлки районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423450, Әлмәт шәһәре, Герцен урамы, 86а йорты адресы буенча урнашкан «Әлмәт шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422350, Апас штп., Шоссе ур., 5 нче йорт адресы буенча урнашкан «Апас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422000, Арча шәһәре, Банк урамы, 6В йорты адресы буенча урнашкан «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422750, Әтнә районы, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан «Әтнә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423930, Баулы шәһәре, Энгельс урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Баулы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422250, Балтач районы, Балтач штп., Совет ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Балтач районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423230, Бөгелмә шәһәре, Октябрь урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан «Бөгелмә шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 159 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Буа шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422570, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Медгородок урамы, 21а йорты адресы буенча урнашкан «Югары Ослан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422701, Биектау авылы, Үзәк урам, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан «Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 нче йорт адресы буенча урнашкан «Чүпрәле районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423600, Алабуга районы, Алабуга шәһәре, Спас урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан «Алабуга шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423520, Зәй районы, Зәй шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 37б йорты адресы буенча урнашкан «Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422550, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 нче йорт адресы буенча урнашкан «Олы Кайбыч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

420034, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 81 нче йорт, А корпусы адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422110, Кукмара шәһәре, Ворошилов урамы, 44 нче йорт адресы буенча урнашкан «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422610, Лаеш шәһәре, Первомайская урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан «Лаеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423250, Лениногорск шәһәре, Гагарин урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан «Лениногорск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422190, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423650, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе, шул исәптән 422230, Әгерҗе шәһәре, К.Маркс урамы, 11а йорты адресы буенча урнашкан «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе филиалы;

423700, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80 нче йорт адресы буенча урнашкан «Минзәлә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423970, Мөслим районы, Пушкин ур., 47 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Мөслим районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423831, Чаллы шәһәре, Сөембикә пр., 47 нче йорт адресы буенча урнашкан «Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе, шул исәптән Тукай районы «Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе филиалы;

423584, Түбән Кама районы, Түбән Кама шәһәре, Бызов ур., 20а йорты адресы буенча урнашкан «Түбән Кама шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423190, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 93 нче йорт адресы буенча урнашкан «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423040, Нурлат шәһәре, Хамадеев урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Нурлат шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422770, Питрәч ав., Совет ур., 20 нче йорт адресы буенча урнашкан «Питрәч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422650, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штб., Завод ур., 6А йорты адресы буенча урнашкан «Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422060, Саба районы, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы, З.Йосыпов ур., 7 нче йорт адресы буенча урнашкан «Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423350, Сарман районы, Сарман авылы, Ленин урамы, 26 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Сарман районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422840, Спас районы, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан «Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422370, Тәтеш шәһәре, Ирек ур., 45 нче йорт адресы буенча урнашкан «Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе, шул исәптән 422820, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штб., К.Маркс ур., 2а йорты адресы буенча урнашкан «Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе филиалы;

422080, Теләче ав., Ленин ур., 73 нче йорт адресы буенча урнашкан «Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423100, Чирмешән ав., Титов ур., 5 нче йорт адресы буенча урнашкан «Чирмешән районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

422980, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан «Чистай шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

423950, Урыссу штп., Пушкин ур., 105/1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

___

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 13 август, 650 нче карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә беркетүгә планлаштырыла торган күчемсез мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Кадастр (инвентарь) номеры | Объект исеме | Адрес (урнашу урыны) | Гомуми мәйдан, кв.метр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Күчемсез милек объектлары | | | | |
| 1. Җир кишәрлеге | | | | |
| 1.1. | 16:44:010131:1260 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Азнакай ш. Төзүчеләр ур., 10 й. | 1 237 |
| 1.2. | 16:03:010121:161 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксубай штп., Романов ур., 6 й. | 225 |
| 1.3. | 16:06:030127:0027 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. | 627,15 |
| 1.4. | 16:55:010105:664 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | 619 |
| 1.5. | 16:12:010119:67 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтая штп., Совет ур., 16 й. | 1 174 |
| 1.6. | 16:46:030102:0050 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Бөгелмә ш., Октябрь ур., з/у 15 | 500 |
| 1.7. | 16:46:030102:0200 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 27 й. | 79,7 |
| 1.8. | 16:47:011211:32 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 2 734 |
| 1.9. | 16:48:060205:9 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Зәй районы, Зәй ш., Нефтьчеләр проспекты, 37 «б» й. | 1 567 |
| 1.10. | 16:49:010202:37 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск ш., участок 1 Май урамы буенча 11 йорт ориентирыннан көньяк-көнбатышка таба 37 метр ераклыкта урнашкан | 33,2 |
| 1.11. | 16:50:100431:144 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Казан ш., Декабристлар ур., 81Г й. | 885 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1.12. | 16:50:160306:5260 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Казан ш., Зорге ур., 102 й. | 1 595 |
| 1.13. | 16:50:100201:4 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | 4 220 |
| 1.14. | 16:51:010402:100 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й. | 686 |
| 1.15. | 16:51:010402:104 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й., 1 корылма, 2 гараж | 33 |
| 1.16. | 16:26:340118:22 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 й. | 962 |
| 1.17. | 16:52:050303:17 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. (43-20) | 4 141 |
| 1.18. | 16:37:010503:10 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. | 153 |
| 1.19. | 16:38:010912:16 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тәтеш ш., Ирек ур., 45 й. | 727 |
| 1.20. | 16:41:080118:0013 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән ав., М.Титов ур., 5 й. | 554,24 |
| 1.21. | 16:54:100402:6 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чистай ш., К.Маркс ур., з/у 35 | 1 499,1 |
| 1.22. | 16:45:020110:83 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт ш., Герцен ур. | 48 |
| 1.23. | 16:45:020110:20 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт ш., Герцен ур., з/у 86А | 3 179 |
| 1.24. | 16:56:010124:7 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Нурлат ш., Р.С.Хамадеев ур., з/у 19 | 900 |
| 1.25. | 16:23:260103:42 | җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара ш. Ворошилов ур., з/у 44 | 2 999 |
| 2. Биналар | | | | |
| 2.1. | 16:44:010103:127 | административ бина | Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Азнакай ш. Төзүчеләр ур., 10 й. | 485 |
| 2.2. | 16:03:010121:247 | административ бина | Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксубай штп., Романов ур., 6 й. | 154,3 |
| 2.3. | 16:03:010101:260 | гараж | Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксубай штп., Толстой ур., 4 «в» й. | 25,8 |
| 2.4. | 16:03:010101:341 | гараж бинасы | Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксуба штп., Совет ур., 3А й. | 31,9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2.5. | 16:06:030130:88 | «Әлки районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе | Татарстан Республикасы, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. | 154,2 |
| 2.6. | 16:06:030127:234 | гараж | Татарстан Республикасы, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. | 62,2 |
| 2.7. | 16:10:010111:132 | гараж | Татарстан Республикасы, Әтнә районы, Олы Әтнә ав., Совет ур., 63/1 гараж | 28,2 |
| 2.8. | 16:55:010105:6110 | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | 342,2 |
| 2.9. | 16:12:010119:158 | прокуратура | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтая штп., Совет ур., 16 й. | 119,7 |
| 2.10. | 16:46:030102:1127 | бина | Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Бөгелмә ш., Октябрьская ур., 15 й. 1000 бүлмә | 828,6 |
| 2.11. | 16:46:030102:200 | гараж | Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 27 й. | 65,1 |
| 2.12. | 16:14:990117:251 | торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Буа районы, Буа ш., Р.Люксембург ур., 35 й. | 43,8 |
| 2.13. | 16:47:011405:9993 | «Ариадна» халыкка социаль-психологик ярдәм үзәге ДУ | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 768,3 |
| 2.14. | 16:47:011211:431 | гараж | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 89,2 |
| 2.15. | 16:48:060205:167 | административ бина | Татарстан Республикасы, Зәй районы, Зәй ш., Нефтьчеләр проспекты, 37 «б» й. | 676 |
| 2.16. | 16:48:060205:118 | хуҗалык блогы (КПП) | Татарстан Республикасы, Зәй районы, Зәй ш., Нефтьчеләр проспекты, 37б й. | 35 |
| 2.17. | 16:48:060205:165 | гараж | Татарстан Республикасы, Зәй районы, Зәй ш., Нефтьчеләр проспекты, 37б й. | 174,5 |
| 2.18. | 16:49:010103:306 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһ., Татарстан ур., 1 й. | 1 051 |
| 2.19. | 16:49:010202:228 | гараж | Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск ш., Мәктәп ур., шәһәр салым инспекциясенең хезмәт гаражыннан көнбатыштарак (Беренче | 26,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | май урамының 11 метрында көньяк-көнбатышка таба юнәлештә) | |
| 2.20. | 16:50:100431:145 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81а й., 1117 бүлмә | 21,1 |
| 2.21. | 16:50:100431:147 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81а й., | 32,6 |
| 2.22. | 16:50:100431:148 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81а й., 1111 бүлмә | 172,2 |
| 2.23. | 16:50:100431:140 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81а, 1031 бүлмә | 53,2 |
| 2.24. | 16:50:100431:141 | административ бинаның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81а й., 1030 бүлмә | 773,8 |
| 2.25. | 16:50:221242:71 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Казан ш., 1-нче Муромская ур., 33А й. 1000 бүлмә | 607,9 |
| 2.26. | 16:50:221242:67 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Казан ш., 1-нче Муромская ур., 33А й. 1001 бүлмә | 16,8 |
| 2.27. | 16:50:070101:158 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Казан ш., Качалов ур., 77 й., 1Н бүлмә | 257,2 |
| 2.28. | 16:50:160306:5685 | торак бинаның беренче катының бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан ш, Зорге ур., 102 й., 1204 бүлмә | 554,1 |
| 2.29. | 16:50:160306:5686 | торак бинаның беренче катының бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан ш, Зорге ур., 102 й., 1203 бүлмә | 58,2 |
| 2.30. | 16:50:160306:5684 | торак бинаның беренче катының бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан ш, Зорге ур., 102 й., 1201 бүлмә | 12,1 |
| 2.31. | 16:50:160306:5687 | торак бинаның беренче катының бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан ш, Зорге ур., 102 й., 1202 бүлмә | 16,1 |
| 2.32. | 16:50:100201:403 | Казан ш. Мәскәү районының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү бюросы бинасы | Татарстан Республикасы, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | 713,5 |
| 2.33. | 16:50:100201:401 | гараж | Татарстан Республикасы, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | 89,9 |
| 2.34. | 16:50:110107:4115 | торак бинаның беренче катының бер өлеше | Татарстан Республикасы, Казан ш., Ибраһимов проспекты, 41 й. 1 бүлмә | 404,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2.35. | 16:50:160205:2805 | торак бинаның беренче каты | Татарстан Республикасы, Казан ш., Абыйлы-энеле Касыймовлар ур., 22/7 й. 1Н бүлмә | 558,1 |
| 2.36. | 16:51:010402:921 | ПТЖХ базасы | Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й. | 684,4 |
| 2.37. | 000000149110049 | гараж | Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й., 1 корылма, 2 бүлмә | 27,1 |
| 2.38. | 16:26:340118:357 | торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 й. | 367,9 |
| 2.39. | 16:52:050303:3841 | торак булмаган бүлмә | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. 1001 бүлмә | 142,5 |
| 5 % | 16:52:050303:3776 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. 1000 бүлмә | 4 113,4 |
| 2.41. | 1000427 | гараж | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Кама Аланы штп. | 24 |
| 2.42. | 16:31:150121:105 | административ бина | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 46 й. | 150,8 |
| 2.43. | 16:37:010503:116 | гараж | Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. 1 корылма | 17,3 |
| 2.44 | 16:37:010503:118 | склад | Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. 2 корылма | 28,9 |
| 2.45. | 16:37:010503:119 | административ бина | Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. 1 бүлмә | 140 |
| 2.46. | 16:38:190101:590 | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тәтеш ш., Ирек ур., 45 й. | 392 |
| 2.47. | 16:38:010912:60 | гараж | Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тәтеш ш., Ирек ур., 45 й. | 38,4 |
| 2.48. | 16:41:030201:3711 | Чирмешән районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән ав., М.Титов ур., 5 й. | 245,33 |
| 2.49. | 16:54:010102:1135 | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., К.Маркс ур., 35 й. | 849,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2.50. | 16:45:010103:383 | Әлмәт шәһәренең «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһәре, Герцен ур., 86 А. | 2 855 |
| 2.51. | 149.11.00001 | үзәк бинасы | Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Нурлат ш., Р.С.Хамадеев ур., 19 й. | 394,6 |
| 2.52. | 16:23:260103:273 | административ бина | Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара ш. Ворошилов ур., 44 й. | 1 076 |
| 3. Бүлмәләр | | | | |
| 3.1. | 16:14:990117:597 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Буа районы, Буа ш., Р.Люксембург ур., 159 й., 1000 бүлмә | 380,5 |
| 3.2. | 16:01:220231:521 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 11А й., 1001 бүлмә | 98,2 |
| 3.3. | 16:53:040303:1695 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20А й.т, 6Н бүлмә | 71,8 |
| 3.4. | 16:53:040303:1696 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20А й.т, 7Н бүлмә | 952,7 |
| 3.5. | 16:30:150308:800 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Кама Аланы штп., 2 нче микрорайон, 2/01 й., 3 бүлмә | 250,9 |
| 3.6. | 16:33:120124:114 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Совет ур., 34 й. 1002 бүлмә | 50,1 |
| 3.7. | 16:40:100406:200 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й., 1 бүлмә | 126,4 |
| 3.8. | 16:40:100406:209 | гаражның бер өлеше | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й. | 40 |
| 3.9. | 16:40:100406:199 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й., 8 бүлмә | 16,2 |
| 3.10. | 16:40:100406:198 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й., 6 бүлмә | 29,9 |
| 3.11. | 16:40:100406:196 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й., 7 бүлмә | 54,5 |
| 3.12. | 16:40:100406:194 | торак булмаган урын | Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 73 й., 2 бүлмә | 18,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4. Корылмалар | | | | |
| 4.1. | 716.12.0108 | катнаш койма | Татарстан Республикасы, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | |
| 4.2. | 16:44:010131:145 | гараж | Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Азнакай ш., Төзүчеләр ур. | 27,6 |
| 4.3. | 16:44:010131:138 | гараж | Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Азнакай ш., Төзүчеләр ур. | 29,1 |
| 4.4. | 716110001 | киртә | Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксубай штп., Романов ур., 6 й. | 36 |
| 4.5. | 759160134 | койма | Татарстан Республикасы, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. | 25 |
| 4.6. | 759120024 | гараж | Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Совет мәйданы, 12 й. | 50 |
| 4.7. | | пандус | Татарстан Республикасы, Баулы районы,  Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | 1 |
| 4.8. | 16:12:010119:187 | гараж | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтая штп., Совет ур., 16 й. | 73,3 |
| 4.9. | 0101340431 | койма | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 28,4 |
| 4.10. | 0101340432 | капка | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 26,4 |
| 4.11. | 01122200001 | киртә | Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | 51,15 |
| 4.12. | 0000002566 | гражданнар белән индивидуаль эш зонасында бренд дивары | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. | |
| 4.13. | 0000002478;2479 | JAX эчке кондиционер ACQ-36HE эчке блогы | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. | |
| 4.14. | 0000002547 | структурлаштырылган кабель системасы (СКС) | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 й. | |
| 4.15. | 000000000000375 | түбән басымлы тышкы газүткәргече, RS-H100 казанының газ җайланмасы | Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара ш. Ворошилов ур., 44 й. | |